| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 2021 ел, 8 июль | г.Казань | № 549 |

2024 елда «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Мәгариф» илкүләм проектына караган «Яшь профессионаллар (Һөнәри белем бирүнең конкурентлык сәләтен арттыру)» федераль проекты кысаларында алга киткән һөнәри әзерләү үзәген оештыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү турында

«Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Мәгариф» илкүләм проектына караган «Яшь профессионаллар (Һөнәри белем бирүнең конкурентлык сәләтен арттыру)» федераль проектының 1.2 нче «100 алга киткән һөнәри әзерләү үзәге оештырылды һәм эшли» дигән нәтиҗәсенә ирешү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын 2024 елда «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Мәгариф» илкүләм проектына караган «Яшь профессионаллар (Һөнәри белем бирүнең конкурентлык сәләтен арттыру)» федераль проекты кысаларында алга киткән һөнәри әзерләү үзәген оештыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү чараларын тормышка ашыру буенча төбәк координаторы итеп билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2024 елда «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Мәгариф» илкүләм проектына караган «Яшь профессионаллар (Һөнәри белем бирүнең конкурентлык сәләтен арттыру)» федераль проекты кысаларында алга

киткән һөнәри әзерләү үзәген оештыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү чаралары тасвирламасын;

2024 елда «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Мәгариф» илкүләм проектына караган «Яшь профессионаллар (Һөнәри белем бирүнең конкурентлык сәләтен арттыру)» федераль проекты кысаларында алга киткән һөнәри әзерләү үзәген оештыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү буенча чаралар комплексын («юл картасын»).

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин